ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ПО БИОЛОГИЧЕСКИМ РЕСУРСАМ
ул. Карима Тинчурина, д. 29, г. Казань, 420021

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ БИОЛОГИК
РЕСУРСЛАР БУЕНЧА
ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ
К. Тинчурин ур., 29 йорт, Казан шәһәре, 420021

Телефон:(843)211-66-94, факс:(843)211-66-47, E-Mail:ojm@tatar.ru, сайт:http://ojm.tatarstan.ru

**Приказ** **г.Казань** **Боерык**

«**12.12.**2019 года № 388-од

2018 елның 16 маеннан 125-од номерлы Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән сирәк һәм бетү куркынычы яный торган төр хайваннарны ирексезлектә асрауга һәм киредән табигатькә кайтаруга рөхсәтнамәләр бирү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

“Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында” 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү турында” Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 16 июнендәге 834 номерлы карары чыгу һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 елның 2 ноябрендәге 310 номерлы “Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентлары системасын эшләү турында”гы карары үз көчен югалту белән бәйле рәвештә, б о е р а м:

1.Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының 2018 елның 16 маеннан 125-од номерлы “Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән сирәк һәм бетү куркынычы яный торган төр хайваннарны ирексезлектә асрауга һәм киредән табигатькә кайтаруга рөхсәтнамәләр бирү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүнең административ регламентын раслау турында”гы боерыгы белән расланган, Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән сирәк һәм бетү куркынычы яный торган төр хайваннарны ирексезлектә асрауга һәм киредән табигатькә кайтаруга рөхсәтнамәләр бирү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүнең

административ регламентына (Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының 2018 елның 14 ноябрендәге 344-од номерлы боерыгы белән кертелгән үзгәрешләр белән) (алга таба-Регламент), аны яңа редакциядә бәян итеп үзгәрешләр кертергә.

2. Рәис урынбасарларына, структур бүлекчәләр җитәкчеләренә, дәүләт хезмәте күрсәтүне турыдан-туры тәэмин итүче затларга Регламент нигезләмәләрен үтәүне тәэмин итәргә һәм алар тарафыннан каралган документларны алып баруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип танырга.

Рәис Ф.С.Батков

12.12.2019 елдан 388-од номерлы боерык редакциясендә Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының 2019 елның 16 маеннан 125-од номерлы боерыгы белән расланды

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ КЫЗЫЛ КИТАБЫНА КЕРТЕЛГӘН СИРӘК ҺӘМ БЕТҮ КУРКЫНЫЧЫ ЯНЫЙ ТОРГАН ТӨР ХАЙВАННАРНЫ ИРЕКСЕЗЛЕКТӘ АСРАУГА ҺӘМ КИРЕДӘН ТАБИГАТЬКӘ КАЙТАРУГА РӨХСӘТНАМӘЛӘР БИРҮ БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ ХЕЗМӘТЕН КҮРСӘТҮНЕҢ АДМИНИСТРАТИВ РЕГЛАМЕНТЫ.

## 1. Гомуми кагыйдәләр.

1.1. Бу Регламент Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән сирәк һәм бетү куркынычы яный торган төр хайваннарны ирексезлектә асрауга һәм киредән табигатькә кайтаруга рөхсәтнамәләр бирү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүнең стандартын һәм тәртибен билгели ( алга таба- дәүләт хезмәте).

1.2. Мөрәҗәгать итүчеләр - физик һәм юридик затлар.

1.3. Дәүләт хезмәте Татарстан республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты белән күрсәтелә ( алга таба – ТР Биоресурслар буенча дәүләт комитеты).

1.3.1. Комитетның урнашу урыны: Казан, Кәрим Тинчурин урамы, 29 йорт.

Комитетның эш вакыты: шимбә һәм якшәмбедән кала, көн саен, дүшәмбе – пәнҗешәмбе 9.00-18.00, җомга 9.00-16.45. Төшке аш 13.00-13.45.

Иҗтимагый транспорт белән “Тинчурин” тукталышына кадәр :

автобуслар № 1, 6, 8, 31, 53, 54, 85, 99, 99 а;

троллейбуслар № 20, 21;

трамвай № 7;

«Ахтямов» тукталышына кадәр:

автобуслар № 5, 23, 56, 68, 72,79.

Бинага керү үткәрү кәгазе яки шәхесне раслый торган документ буенча.

Комитетның район ( районара) бүлекләренең эш тәртибе:

дүшәмбе, пәнҗешәмбе, җомга,шимбә, якшәмбе 9.00-18.00.

Ял көннәре сишәмбе,чәршәмбе

Төшке аш 13.00-13.45.

Гаризаларны кабул итү графигы: дүшәмбе, пәнҗешәмбе, җомга, шимбә, якшәмбе көннәрне Комитетның район (районара) бүлекләренең эш сәгатьләрендә.

1.3.2. ТР Биоресурслар буенча дәүләт комитетының биотөрлелек бүлегенең (

алга таба – Бүлек) белешмәләр өчен телефоны : (843)211-70-78.

1.3.3. Мәгълүмати-телекоммуникатив “Интернет” челтәрендә Комитетның рәсми сайт адресы http://www.ojm.tatar.ru.

1.3.4.Дәүләт хезмәте турында мәгълүмат түбәндәге юллар белән алынырга мөмкин:

1) мәгълүмати-телекоммуникатив “Интернет” челтәре аша http://www.ojm.tatar.ru сайтында;

Татарстан Республикасының Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi.tatar.ru/);

Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталында (http://www.gosuslugi.ru);

2) ТР Биоресурслар буенча дәүләт комитетына телдән мөрәҗәгать итеп (телефон аша (843)211-70-78 яки шәхси (102 кабинет));

3) ТР Биоресурслар буенча дәүләт комитетына язмача мөрәҗәгать итеп (шул санда ojm@tatar.ru рәсми электрон почтага җибәрелгән электрон документ рәвешендә).

4) ТР Биоресурслар буенча дәүләт комитеты биналарында дәүләт хезмәте турында турыдан-туры күреп һәм текстлы мәгълүмат булган, дәүләт хезмәте турында мәгълүмати стендлар ярдәмендә.

Мәгълүмати стендларда урнаштырылган мәгълүмат, дәүләт хезмәте турында, бу Регламентның 1.3.1, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.8, 2.10, 2.11, 5.1 пунктларында бирелгән мәгълүматны үз эченә ала.

1.3.5. Комитетның урнашу урыны, белешмә телефоннары, эш графигы, рәсми сайт адресы, электрон почтасы, Комитетның рәсми сайтында, «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасында, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында урнаштырыла.

Комитетның мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү биналарындагы мәгълүмати стендларда урнаштырылган мәгълүмат, Татарстан Республикасының дәүләт телләрендә урнаштырыла һәм үз эченә дәүләт хезмәте турында әлеге Регламентның 1.3.1, 2.1, 2.3 - 2.5, 2.7, 2.9, 2.11, 5.1 нче пунктларда күрсәтелгән мәгълүматны ала.

1.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү түбәндәге актлар белән җайга салына:

24.04.1995 елдан № 52-ФЗ “Хайваннар дөньясы турында”гы Федераль закон белән; (алга таба – № 52-ФЗ Федераль закон) (РФ законнар җыентыгы, 24.04.1995, № 17, 1462 ст., кертелгән үзгәрешләрне истә тотып);

10.01.2002 елдан № 7-ФЗ “ Тирә-як мохитне саклау турында”гы Федераль закон белән (Россия Федерациясенең законнар җыентыгы, 2002, № 12, 133 ст., кертелгән үзгәрешләрне истә тотып);

27.07.2010 елдан № 210-ФЗ “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында”гы Федераль закон белән (Россия Федерациясенең законнар җыентыгы, 02.08.2010, №31, 4179 ст., кертелгән үзгәрешләрне истә тотып);

06.04.2011 елдан № 63-ФЗ “Электрон имза турында”гы Федераль закон белән ( алга таба-№ 63-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясенең законнар җыентыгы, 2011, № 15, 2036 ст., кертелгән үзгәрешләрне истә тотып);

07.05.2012 елдан 601 номерлы “Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең

төп юнәлешләре турында”гы Россия Федерациясе Президенты Боерыгы (алга таба – 601 номерлы РФ Президенты Боерыгы) (Россия Федерациясенең законнар җыентыгы, 2012, № 19, 2338ст.);

25.07.1973 елдан СССР Мәдәният министрлыгы тарафыннан расланган, СССР Зоопарклар (зообакчалар) өчен һәвефсезлек техникасы һәм сәнәгый санитария кагыйдәләре белән (алга таба - Зоопарклар өчен һәвефсезлек техникасы һәм сәнәгый санитария кагыйдәләре)( Реклама нәшрияты,1974);

Татарстан Республикасының Экология Кодексы белән (алга таба – ТР ЭК) (Татарстанның Дәүләт Киңәшмәсе Хәбәрләре, 2009, №1, 5 ст., кертелгән үзгәрешләрне истә тотып);

30.01.2001 елдан 41 номерлы “Татарстан республикасының кызыл китабына кертелгән сирәк һәм бетү куркынычы яный торган төр хайваннарны ирексезлектә асраугa һәм киредән табигатькә кайтаруга рөхсәтнамәләр бирү тәртибен раслау турында” Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган, Татарстан республикасының кызыл китабына кертелгән сирәк һәм бетү куркынычы яный торган төр хайваннарны ирексезлектә асраугa һәм киредән табигатькә кайтаруга рөхсәтнамәләр бирү тәртибе белән ( алга таба – ТР МК 41 нче боерыгы белән расланган Тәртип) (“Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият әгъзаларының норматив актлары җыелмасы” журнал, 2005, №33-34, кертелгән үзгәрешләрне истә тотып);

06.02.2001 елдан №57 “Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән, сирәк һәм бетү куркынычы яный торган төр хайваннарны һәм үсемлекләрне куллануга рөхсәтнамә бирү тәртибе турында”гы Татарстан Республикасының Министрлар Кабинеты боерыгы белән расланган, Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән, сирәк һәм бетү куркынычы яный торган төр хайваннарны һәм үсемлекләрне куллануга рөхсәтнамә бирү тәртибе белән ( алга таба- ТР МК №57 боерыгы белән расланган Тәртип) (“Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият әгъзаларының норматив актлары җыелмасы” журнал, 2012, №64, 2464 ст., кертелгән үзгәрешләрне истә тотып);

02.11.2010 елдан “Татарстан Республикасының башкарма хакимият әгъзаларының хезмәт күрсәтүләре буенча адмистратив регламентларны эшләү һәм раслау Тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгешләр кертү турында ”гы 880 номерлы Татарстан Республикасы министрлар Кабинетының карары (алга таба –ТРМК 880 номерлы карары)(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карарлар һәм күрсәтмәләр һәм республика башкарма хакимият әгъзаларының норматив актлары җыентыгы, 08.12.2010, № 46,2144 ст., кертелгән үзгәрешләр белән);

15.12.2017 елдан 996 номерлы “Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты турында Кагыйдәнамәне раслау турында”гы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карары ( алга таба – Комитет турында Кагыйдәнамә) (Татарстан Республикасының законнар җыентыгы, 2017, № 95, 3544 ст., кертелгән үзгәрешләрне истә тотып).

1.5. Бу регламентта киләсе атамалар һәм билгеләмәләр кулланыла:

хайваннар дөньясы – Россия Федерациясе территориясендә даими рәвештә

яки вакытлыча яши торган һәм табигый азатлыкта булган, ә шулай ук Россия Федерациясенең континенталь шельф табигый байлыкларына һәм икътисади зонасына карый торган барлык төр кыргый хайваннарның тере организмнар барлыгы.

хайваннар дөньясы объекты - хайваннар чыгышына караган организм ( кыргый хайван);

Киредән табигатькә кайтару (реинтродукция) –кыргый хайваннарны табигый мохиткә чыгару, ирексез шартларда тотылган яки туган кыргый хайваннарны табигатькә чыгару;

кыргый хайваннарны ирексезлектә тоту- хайваннарны вакытлыча яки даими рәвештә вольерларда, читлекләрдә, киртәләрдә тоту.

ВЭХС - Ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы;

техник хата – дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган тарафыннан ясалган һәм документка кертелгән мәгълүматларның(дәүләт хезмәте нәтиҗәсе), алар нигезендә мәгълүматлар кертелгән документларга тәңгәл килмәвенә китергән **хата**(хәреф хатасы, грамматик яки арифметик хата).

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкнең читтән торып эш урыны- Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 22 декабреннән “Күп функцияле үзәкләр тарафыннан дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү эшчәнлегенең кагыйдәләрен раслау турында”гы 1376 нчы карары белән расланган , Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру Кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы муниципаль районының (шәһәр округының) шәһәр яки авыл җирлегендә төзелгән дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкнең территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офис).

Бу Регламентта дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гариза астында ( алга таба – гариза) дәүләт хезмәтен күрсәтү турында мөрәҗәгать күз алдында тотыла (210-ФЗ номерлы Федераль законның 2 нче ст. 2 пункт). Гаризаның тәкъдим ителгән формасы, ТР МК 41нче номерлы карары белән расланган Тәртипнең 2нче кушымтасында бирелгән (Әлеге Регламентка 1 нче кушымта)

## 2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү стандарты

| Дәүләт хезмәтен күрсәтү стандартына куела торган таләпнең исеме | Стандартка куела торган таләпнең эчтәлеге | Таләпне яки дәүләт хезмәтен билгели торган норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1.Дәүләт хезмәтенең атамасы | Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән сирәк һәм бетү куркынычы яный торган төр хайваннарны ирексезлектә асрауга һәм киредән табигатькә кайтаруга рөхсәтнамәләр бирү | 52-ФЗ номерлы Федераль канунның 26 ст. ;<br>ТР МК 41 номерлы боерыгы белән расланган Тәртип |
| 2.2. Башкарма хакимият органының исеме | Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты | Комитет турында Кагыйдәнамә , ТР МК 41 номерлы боерыгы белән расланган<br>Тәртипнең 1.7 пункты |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенең тасвирламасы | Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән, сирәк һәм бетү куркынычы яный торган төр хайваннарны ирексезлектә асрауга һәм киредән табигатькә кайтаруга рөхсәтнамә<br>Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән, сирәк һәм бетү куркынычы яный торган төр хайваннарны ирексезлектә асрауга һәм киредән табигатькә кайтаруга рөхсәтнамә бирмәү турында хат | ТР МК 41 номерлы боерыгы белән расланган Тәртипнең 3.1. пункты |

| | | |
|---|---|---|
| 2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын исәпкә алып, әгәр Россия Федерациясе законнарында каралса, Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору вакыты, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документларны бирү (җибәрү) вакыты. | Рөхсәтнамәне бирү( рөхсәтнамә бирүдән баш тарту) турында карарны кабул итү,гариза теркәлгәннән соң 22 эш көне эчендә үтәлә.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтү вакытын туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.<br>Дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булган документны бирү мөрәҗәгать итүче килгән көнне гамәлгә ашырыла. | ТР МК 41 номерлы боерыгы белән расланган Тәртипнең 3.6.,3.7.пунктлары |
| 2.5. Дәүләт хезмәте, шулай ук мөрәҗәгать итүчегә күрсәтелергә тиешле дәүләт хезмәтләрен күрсәтү өчен зарури һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәтү өчен закон яки башка норматив-хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге,гариза бирүче белән аларны алу ысуллары, шул | 1. Бу Регламентның 1нче кушымтасында тәкъдим ителгән форма буенча гариза.<br>2. Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән, сирәк һәм бетү куркынычы яный торган төр хайваннарны ирексезлектә асрауга һәм киредән табигатькә кайтаруга элек бирелгән рөхсәтнамәне куллану турында отчет ( бирелгән булса)<br>3. Гариза бирүченең Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән, сирәк һәм бетү куркынычы яный торган төр хайваннарны ирексезлектә яки ясалма яшәү тирәлегендә асрауга һәм киредән табигатькә кайтаруга җаваплы белгеч белән эш яки гражданлык-хокукый килешүнамәсенең күчермәсе (гариза бирүче үзе җаваплы зат | ТР МК 41 номерлы боерыгы белән расланган Тәртипнең 2нче кушымтасы 3.2. пункты |

| | | |
|---|---|---|
| санда электрон рәвештә, аларны күрсәтү тәртибе. | булып килгән очраклардан кала)<br>4.Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән, сирәк һәм бетү куркынычы яный торган төр хайваннарны ирексезлектә яки ясалма яшәү тирәлегендә асрауга һәм киредән табигатькә кайтаруга җаваплы белгечнең югары профильле белеме булуын раслаучы документның күчермәсе (ветеринария, зоотехния, биология, зоология).<br>5.Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән, хайваннарны ирексезлектә яки ясалма яшәү тирәлегендә тоту шартлары турында, ә шулай ук аларны киредән табигатькә кайтару турында мәгълүмат.<br>Дәүләт хезмәтен алыр өчен гариза бланкын гариза бирүче шәхси ТР Биоресурслар буенча дәүләт комитетыннан алырга мөмкин.<br>Бланкның электрон формасы ТР Биоресурслар буенча дәүләт комитетының рәсми сайтында урнаштырылган.<br>Гариза һәм аңа кушылган документлар, гариза бирүче белән, кәгазьдә киләсе ысуллар белән тапшырыла алалар:<br>шәхси (ышанычнамә нигезендә гариза бирүче исеменнән эш итүче зат белән);<br>почта аша.<br>Документлар, гариза бирүче белән, шулай ук электрон рәвештә, электрон имза белән расланып, интернет челтәре аша яки Татарстан Республикасының Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша тапшырыла ала. | |
| 2.6. Дәүләт органнары, җирле | Электрон ведомствоара бәйләнеш системасы буенча алына: | |

| | | |
|---|---|---|
| үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагындагы, дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен норматив-хокукый актлар нигезендә, гариза бирүче тапшырырга хокуклы булган кирәкле документларның тулы исемлеге, ә шулай ук гаризачылар белән аларны алу ысуллары, шул санда электрон рәвештә;аларны бирү тәртибе. | Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән сирәк һәм юкка чыгу куркынычы янаган хайваннарның һәм үсемлекләрнең законлылыгын раслаучы документлар (белешмәләр). Россия Федерациясе субъектының мондый төр хайваннарның килеп чыгышы урынында әлеге мәсьәләне алып баручы башкарма органыннан соратып алына.<br>Документларны бирү ысуллары һәм алу тәртибе, бу Регламентның 2.5. пунктында билгеләнгән.<br>Гариза бирүчедән киләсе документларны таләп итү тыела:<br>дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда тапшыру яисә аларны гамәлгә ашыру каралмаган гамәлләрне гамәлгә ашыру өчен документлар һәм мәгълүмат бирү;<br>210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 6 өлешендә күрсәтелгән документлардан тыш, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтүче дәүләт органнары, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешмалар карамагында булган дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләр өчен түләү кертүне раслаучы документлар һәм мәгълүмат.<br>210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктында каралган очраклардан тыш, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны беренчел кабул | |

| | | |
|---|---|---|
| | итүдән баш тартканда яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда аларның булмавы һәм (яисә) дөреслеге күрсәтелмәгән документлар һәм мәгълүмат бирү. | |
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Бу Регламентның 2.5. пунктында күрсәтелгән документларның берәрсен тапшырмау. | ТР МК 41 номерлы боерыгы белән расланган Тәртипнең 3.2. пункты |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яки дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен законнар белән нигезләр каралмаган.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр юк: | 52-ФЗ номерлы Федераль законның 19 ст. ;<br>Зоопарклар өчен һәвефсезлек техникасы һәм сәнәгый санитария кагыйдәләренә 8 нче кушымта;<br>ТР МК 41 номерлы боерыгы белән расланган Тәртипнең 3.8. пункты |
| 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасы яки башка төрле түләүнең тәртибе, күләме һәм алу нигезләре | Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр исемлеге, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешмалар тарафыннан бирелә торган документ (документлар) турында белешмәләр | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |
| 2.11. Мондый түләү күләмен исәпләү методикасы турындагы мәгълүматны кертеп, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтүгә түләүне алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |
| 2.12. Дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы оешма тарафыннан күрсәтелә торган дәүләт хезмәтен күрсәтү турында запрос биргәндә һәм мондый хезмәтләрне күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта торуның максималь вакыты | Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы запросны биргәндә һәм мондый хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта торуның максималь вакыты 15 минуттан да артмаска тиеш.<br>Дәүләт хезмәтләрен алучыларның аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән. | РФ Президентының 601 нче номерлы указы |
| 2.13. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүдә | Гариза кергән көнне.<br>Электрон рәвештә, ял (бәйрәм) көнендә кергән мөрәҗәгать, | |

| | | |
|---|---|---|
| катнашучы оешма тарафыннан күрсәтелә торган дәүләт хезмәте һәм хезмәтләр күрсәтү турында, шул исәптән электрон формада да, соратып алуны теркәү вакыты һәм тәртибе | ял (бәйрәм) көненнән соң килгән эш көнендә теркәлә. | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урыннарга, көтү залына, дәүләт хезмәте күрсәтү турында запросларны тутыру урыннарына, аларны тутыру үрнәкләренә һәм һәр дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар исемлегенә, мондый хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текст һәм мультимедиа мәгълүматларын урнаштыру һәм рәсмиләштерү, шул исәптән федераль законнар һәм инвалидларны социаль яклау турында Татарстан Республикасы законнары нигезендә инвалидлар өчен күрсәтелгән объектларга керү мөмкинлеген тәэмин итүгә карата таләпләр | Дәүләт хезмәтен күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырылган биналарда һәм бүлмәләрдә башкарыла.<br>Инвалидларның дәүләт хезмәте күрсәтү урынына тоткарлыксыз керә алуы тәэмин ителә (бинага керү-чыгу һәм алар чикләрендә күчү уңайлы).Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында визуаль, текст һәм мультимедиа мәгълүматы инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла. | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.15. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдалану мөмкинлеге һәм сыйфаты күрсәткечләре, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәткәндә вазыйфаи затлар белән хезмәттәшлеге саны һәм аларның дәвамлылыгы, дәүләт хезмәте күрсәтүнең барышы турында мәгълүмат алу мөмкинлеге, шул исәптән мәгълүмати-коммуникацион технологияләр кулланып, дәүләт хезмәтен күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә (шул исәптән тулы күләмдә) дәүләт хезмәтен алу мөмкинлеге , башкарма хакимият органының теләсә кайсы территориаль бүлекчәсендә мөрәҗәгать итүчене сайлау буенча (экстерриториаль принцип), Федераль законның 15.1 статьясында каралган дәүләт һәм муниципаль | Дәүләт хезмәтеннән файдалана алу мөмкинлеге күрсәткечләре:<br>Комитет биналарының җәмәгать транспортына үтемлелек зонасында урнашуы;<br>кирәкле белгечләр саны, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул ителә торган бүлмәләр булу;<br>дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарны инвалидлар өчен уңайлы итү;<br>инвалидларга башка затлар белән беррәттән хезмәт күрсәтүгә комачаулаучы башка киртәләрне җиңеп чыгуда ярдәм күрсәтү;<br>мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендә, Комитетның рәсми сайтында дәүләт хезмәте күрсәтүнең ысуллары, тәртибе, сроклары турында тулы мәгълүмат булу;<br>гаризаны электрон рәвештә бирү мөмкинлеге булу.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләре булып түбәндәгеләр тора:<br>документларны кабул итү һәм карап тикшерү срокларын үтәү;<br>дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алу срогын үтәү;<br>Комитет белгечләре тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү барышында бу регламентны бозу турында нигезле шикаятьләр булмау;<br>гариза бирүченең Комитет белгечләре белән аралашу саны:<br>-дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны шәхси тапшырганда - ике тапкырдан да артмау (консультацияләрне санамыйча) ; | |

| | | |
|---|---|---|
| хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләрендә берничә дәүләт һәм (яки) муниципаль хезмәт күрсәтү турында соратып алу юлы белән (комплексы запрос ) | -дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны почта аша яки электрон рәвештә тапшырганда – бердән дә артмау.<br>Дәүләт хезмәте күрсәткәндә гариза бирүченең Комитет (бүлек)яки КФҮ белгече белән хезмәттәшлек дәвамлылыгы 15 минуттан артмый.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү, шул санда дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гариза бирү күп функцияле үзәк, аның ераклашкан эш урыны аша гамәлгә ашырылмый.<br>Экстерриториаль принцип буенча яки комплекслы соратып алу составында дәүләт хезмәте күрсәтелми.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең барышы турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан ТР Биоресурслар буенча дәүләт комитеты сайтында (http://ojm.tatarstan.ru), Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең бердәм порталында(https://www.gosuslugi.ru), Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi.tatarstan.ru) алырга мөмкин. | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.16. Башка таләпләр, шул исәптән экстерриториаль принцип буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең үзенчәлекләрен исәпкә алучы (дәүләт хезмәте экстерриториаль принцип буенча бирелгән очракта) һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләре | Консультация телефон аша шәхси яки электрон хәбәр формасында электрон почта аша (e-mail: ojm@tatar.ru) Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең рәсми порталындагы Интернет-кабул итү бүлмәсе аша) http://ojm.tatarstan.ru) бирелергә мөмкин.<br>Гариза һәм документлар электрон рәвештә Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләр) бердәм порталы, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша җибәрелә. Алга таба документларның оригиналлары күрсәтелә. | |

3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм башкару сроклары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләр) электрон рәвештә үтәү үзенчәлекләре

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәткәндәге гамәлләрнең эзлеклелек тасвирламасы

3.1.1. Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән сирәк һәм бетү куркынычы яный торган төр хайваннарны ирексезлектә асрауга һәм киредән табигатькә кайтаруга рөхсәтнамәләр бирү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтү үз эченә түбәндәге процедураларны кертә:

гариза бирүчене консультацияләү, шул санда гариза бирүчегә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны тутырырга булышу;

документларны кабул итү һәм гаризаны теркәү;

документларны тикшерү, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара запросларны формалаштыру һәм җибәрү;

биологик экспертиза үткәрү;

рөхсәтнамәне бирү яки рөхсәтнамә бирүдән баш тарту турында карар кабул итү;

гариза бирүчегә дәүләт хезмәте нәтиҗәсен бирү;

техник хатаны төзәтү.

3.2.Гариза бирүчене консультацияләү, шул санда гариза бирүчегә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны тутырырга булышу.

Гариза бирүче, дәүләт хезмәтен алу тәртибе турында консультация , шул санда гариза бирүчегә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны тутырырга булышлык алырга дип шәхси, телефоннан һәм (яки) электрон почта аша, Бүлеккә мөрәҗәгать итә.

Бүлек белгече, гариза бирүчегә консультация бирә, шул исәптән документларның формасы, составы, эчтәлеге буенча һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны тутырырга булыша.

Бу пункт белән билгеләнгән процедура гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: консультация, бирелгән документларның формасы, составы, эчтәлеге, аларны тутыру буенча булышлык.

3.3. Гаризаны кабул итү һәм теркәү, гаризаны һәм документларны Бүлеккә җибәрү яки гариза бирүчегә кире кайтару.

3.3.1. Гариза бирүче шәхси, вәкаләтле заты аша, почта аша яки электрон рәвештә, бу Регламентның 2.5 пункты белән туры килеп,дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гариза һәм документларны тапшыра.

Бүлек белгече:

гариза бирүче, ышаныч кәгазе буенча эш иткән очракта, гариза бирүченең вәкаләтләрен тикшерә;

барлык кирәк булган документларның булуын һәм аларның билгеләнгән таләпләргә туры килүен ( документларны дөрес тутыру, документларда чистарту, өстәмә язу, сызылган сүзләр һәм башка төзәтүләр булмауны) тикшерә.

Бу регламентның 2.8. пункты белән каралган, документларны кабул итмәслек

нигезләр булган очракта, Бүлек белгече гариза бирүчегә документларын кире кагу турында хәбәр итә һәм ачыкланган, документларны кабул итәргә комачаулый торган, нигезләрнең эчтәлеген язмача аңлатып, документларны кире кайтара.

Кире кагуга нигезләр булмаган очракта оештыру эше бүлеге белгече, гаризаны кабул итә һәм терки.

Гариза бирүче бүлеккә гаризаны электрон рәвештә тапшырган очракта, аны теркәү өчен нигез булып, бу Регламентның 2.5. пунктында күрсәтелгән, Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша җибәрелгән, документлар килә.

Бу пункт белән билгеләнгән процедуралар, гариза кергән көнне үтәләләр.

Процедуралар нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән яки гариза бирүчегә кире кайтарылган документлар.

3.3.2. Рәис хатны раслый һәм башкару үзенчәлекләре буенча билге куеп, Бүлеккә җибәрә.

Бу пункт белән билгеләнгән процедура, гариза теркәлгән вакыттан алып бер көн эчендә үтәлә.

Процедураның нәтиҗәсе: Бүлеккә җибәрелгән хат.

3.3.3. Җаваплы башкаручыны билгеләү һәм аңа гаризаны тапшыру, кисәтүләрне бетерү кирәклеге турында мөрәҗәгать итүчегә белдерү.

Бүлек башлыгы җаваплы башкаручыны билгели (алга таба - Бүлек белгече) һәм аңа гариза һәм документларны карау өчен тапшыра.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар гариза теркәлгән көннән алып бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Бүлек белгеченә тапшырылган гариза һәм документлар.

3.4. Документларны тикшерү, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара запрос формалаштыру һәм җибәрү.

3.4.1. Бүлек белгече::

гариза бирүченең эшен формалаштыра;

әлеге Регламентның 2.5 пункты нигезендә документларны тикшерә;

юкка чыгу куркынычы астында булган хайваннар төрләренең барлыкка килү урыннарыннан Россия Федерациясе субъектының башкарма хакимият органына мәгълүмат турында ВЭХС аша ведомствоара запрос җибәрә;

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар алдагы процедураны тәмамлаганнан соң өч эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: документларны тикшерү, ведомствоара запрослар җибәрү.

3.4.2. Мәгълүмат белән тәэмин итүчеләр белгечләре ВЭХС аша кергән запрослар нигезендә соратып алына торган мәгълүматны тапшыралар.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар законда билгеләнгән срокларда гамәлгә ашырыла.

3.4.3. Гариза бирүче белән бирелгән документларда, техник хаталар булса яки рәсмиләштерүгә куелган таләпләргә туры килмәсә, Бүлек белгече гариза бирүчене телефон аша, электрон почта аша һәм (яки) почта аша кисәтүләрне төзәтергә

кирәклеге турында белдерә.

Бу пункт белән билгеләнгән процедуралар, алдагы процедура тәмамланганнан соң, ике эш көне эчендә үтәләләр.

Процедуралар нәтиҗәсе: кисәтүләрне төзәтергә кирәклеге турында гариза бирүчегә белдерү.

3.4.4 Әгәр дә биш көн эчендә, гариза бирүче белән, документларның составы һәм эчтәлеге буенча кисәтүләр бетерелмәсә, Бүлек белгече сәбәпләрен күрсәтеп, дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту турында хат әзерли һәм аны гариза бирүчегә җибәрә.

Бу пункт белән билгеләнгән процедуралар, кисәтүләрне бетерү вакыты узганнан соң, ике эш көне эчендә үтәләләр.

3.5. Күрсәтелгән хайван буенча биологик экспертиза уздыру.

Бүлек белгече:

Эшнең биологик экспертизасын уздыру:

регионда карала торган хайваннар дөньясы объектларының саны билгеләнә;

соралган данә санын тартып алу мөмкинлеге, эшчәнлек төренең әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынтысынең дәрәҗәсен билгеләү;

биологик экспертиза нәтиҗәсен әзерләү;

рөхсәтнамәне бирү яки аны бирүдән баш тарту турында карар кабул итү өчен, нәтиҗәне Бүлек башлыгына юнәлтү.

Бу пункт белән билгеләнгән процедуралар, 3.4.1. пункты белән каралган процедура тәмамланганнан соң, биш эш көне эчендә үтәләләр.

Процедура нәтиҗәсе: биологик экспертиза нәтиҗәсе.

3.6. Рөхсәт бирү яки бирүдән баш тарту турында карар кабул итү:

3.6.1. Бүлек башлыгы гариза бирүченең эшен, биологик экспертиза бәяләмәсен карый һәм рөхсәтнамә бирү яки рөхсәтнамә бирүдән баш тарту турында карар кабул итә һәм кабул ителгән карарны Бүлек белгеченә җибәрә.

Рөхсәтнамә бирүдән баш тарту өчен нигез булып тора:

мөрәҗәгать итүче тарафыннан бирелгән документларда дөрес булмаган мәгълүмат булу;

хайваннарны тоту шартларының рөхсәт ителгән кагыйдәләргә һәм нормаларга туры килмәве.

Процедура 3.5 пунктында каралган процедура тәмамланганнан соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: рөхсәтнамә бирү яки рөхсәтнамә бирүдән баш тарту турында карар.

3.7. Хат проектын, рөхсәтнамә проектын әзерләү һәм аны яраштыру.

3.7.1. Бүлек белгече, рөхсәтнамәне бирү яки аны бирүдән баш тарту турындагы карар нигезендә:

рөхсәтнамәне бирү яки аны бирүдән баш тарту турында хат проектын әзерли;

Татарстан республикасының Кызыл китабына кертелгән сирәк һәм бетү куркынычы яный торган төр хайваннарны ирексезлектә асрауга һәм киредән табигатькә кайтаруга рөхсәтнамә проектын әзерли;

әзерләнгән проектларны Бүлек башлыгына яраштыруга җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар 3.6 пунктта каралган

процедура тәмамланганнан соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: Бүлек башлыгына яраштыруга җибәрелгән, Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән сирәк һәм бетү куркынычы яный торган төр хайваннарны ирексезлектә асрауга һәм киредән табигатькә кайтаруга рөхсәтнамә бирү яки аны бирүдән баш тарту турында хат проекты, һәм рөхсәтнамә проекты.

3.7.2. Бүлек башлыгы әзерләнгән проектларны яраштыра һәм кул куярга Рәискә юнәлтә.

Бу пункт белән билгеләнгән процедура, алдагы процедура тәмамланганнан соң, бер эш көне эчендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: кул куярга җибәрелгән, яраштырылган проектлар.

3.7.3. Рәис хатка, Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән сирәк һәм бетү куркынычы яный торган төр хайваннарны ирексезлектә асрауга һәм киредән табигатькә кайтаруга рөхсәтнамәгә яки рөхсәтнамә бирүдән баш тарту турында хатка кул куя һәм Бүлекккә юнәлтә.

Бу пункт белән билгеләнгән процедура, алдагы процедура тәмамланганнан соң, бер эш көне эчендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: Бүлеккә юнәлтелгән, кул куелган хат, рөхсәтнамә яки кире кагу турында хат.

3.8. Рөхсәтнамәне почта аша җибәрү(бирү).

Бүлек белгече гариза бирүчегә, рөхсәтнамәне кушып, рөхсәтнамә бирү турында хат яки сәбәпләрен күрсәтеп, рөхсәтнамә бирүдән баш тарту турында хат җибәрә.

Бу пункт белән билгеләнгән процедуралар, алдагы процедура тәмамланганнан соң, бер эш көне эчендә үтәләләр( гариза бирүче килгән көнне).

Процедура нәтиҗәсе:

Результат процедур: рөхсәтнамәне кушып, рөхсәтнамә бирү турында яки рөхсәтнамә бирүдән баш тарту турында почта аша җибәрелгән хат.

3.9. Техник хаталарны төзәтү( хәреф хатасы, арифметик яки грамматик хата)

3.9.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документта техник хата табылган очракта, гариза бирүче Бүлеккә түбәндәге документларны тапшыра:

техник хатаны төзәтү турында гариза ( бу регламентка 3нче кушымта);

гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып бирелгән, техник хатасы булган документ;

юридик көчкә ия булган,техник хата булуны дәлилләүче документлар.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документтагы мәгълүматларда, техник хатаны төзәтү турында гариза, гариза бирүче белән (аның вәкаләтле заты белән) шәхси, яки почта аша (шул санда электрон почта аша), яки Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша бирелә.

3.9.2.Оештыру эше бүлегенең белгече техник хатаны төзәтү турында гаризаны һәм аңа кушылган документларны кабул итә һәм гаризаны электрон рәвештә идарәара электрон мөнәсәбәт системасы аша терки.

Бу пункт белән урнаштырыла торган процедура, гариза бирелгән көнне үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: тикшерүгә җибәрелгән, кабул ителгән һәм теркәлгән гариза.

3.9.3.Бүлек белгече дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документка төзәтүләр кертү максаты белән документны тикшерә, төзәтелгән документны гариза бирүчегә (вәкаләтле вәкиленә) имза астына шәхси тапшыра, гариза бирүчедән (вәкаләтле вәкиленнән)техник хатасы булган төп нөсхәсен кире ала, яки гариза бирүченең (вәкаләтле вәкиленең) адресына почта аша, Бүлеккә техник хатасы булган документның төп нөсхәсен алып килгән вакытта, документ алу мөмкинлеге булу турында хат җибәрә.

Бу пункт белән урнаштырыла торган процедура, техник хатаны тапканнан яки теләсә кайсы кызыксынган заттан техник хата җибәрү турында гариза алганнан соң, өч эш көне эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: гариза бирүчегә тапшырылган (юнәлтелгән документ).

## 4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү артыннан тикшерү тәртибе һәм формалары

4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгы һәм сыйфаты артыннан тикшерү, гариза бирүчеләрнең хокукларын бозуларны ачыклауны һәм бетерүне, шикаятьләрне карауны, тикшерүләр үткәрүне, карарлар кабул итүне һәм гариза бирүчеләрнең сорауларына җаваплар әзерләүне, ТР Биоресурслар буенча дәүләт комитетының вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карарлар әзерләүне үз эченә кертә.

Административ процедураларны үтәүне саклау артыннан тикшерү формалары:

- Дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча документ проектларының экспертизасын уздыру. Экспертиза нәтиҗәсе булып проектларны раслау тора;
- билгеләнгән тәртиптә эш башкаруны алып баруны тикшерү;
- билгеләнгән тәртиптә контроль тикшерүләр уздыру.

Тикшерүләрне уздыруның кабатлануы планлы (ТР Биоресурслар буенча дәүләт комитетының еллык яки ярты еллык эш планнары нигезендә башкарыла) һәм планнан тыш (гариза бирүченең мөрәҗәгате буенча) характер йөртә. Тикшерү вакытында дәүләт хезмәтен күрсәтү белән бәйле булган барлык сораулар карала ала(комплекслы тикшерүләр), яки гариза бирүченең конкрет мөрәҗәгате буенча. Әлеге Регламентның 3 бүлегендә билгеләнгән, административ процедуралар үтәлү артыннан тикшерүне гамәлгә ашыру максаты белән, дәүләт хезмәтен күрсәткәндә һәм карарлар кабул иткәндә, Рәискә дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәләре турында белешмә тапшырыла.

4.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча, административ процедуралар белән билгеләнгән, гамәлләр эзлеклелеген тотуны агымдагы тикшерү, биотөрлелек бүлегенең башлыгы белән гамәлгә ашырыла.

4.3. Агымдагы тикшерүне үтәүче вазыйфаи затлар исемлеге, ТР Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты бүлекләре турында һәм вазыйфаи регламентлар белән билгеләнә.

Агымдагы тикшерүне үтәүнең кабатланып торуы Рәис белән урнаштырыла.

Тикшерүләрне уздыру нәтиҗәләре буенча, гариза бирүчеләрнең хокуклары бозылу ачыклаган очракта, дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен җаваплы вазыйфаи затлар, Россия Федерациясе кануннары белән каралган тәртиптә җаваплылыкка тарттырылалар.

4.4. Рәис, гариза бирүчеләрнең мөрәҗәгатьләре үз вакытында каралуын, тикшерүне тәэмин итә.

Бүлек башлыгы, әлеге Регламентның 3 бүлегендә билгеләнгән, административ процедуралар үз вакытында үтәлмәү яки начар үтәлү өчен җаваплы.

Җаваплы башкаручы үз вакытында каралмаган яки начар каралган мөрәҗәгатьләр өчен җаваплы.

4.5. Гариза бирүчеләр ягыннан дәүләт хезмәтен күрсәтү артыннан тикшерү, гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтелүне контрольдә тоту дәүләт хезмәтен күрсәткәндә ТР Биоресурслар буенча дәүләт комитетының ачык эшчәнлегендә, дәүләт хезмәтен күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм дөрес мәгълүмат алганда һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карау мөмкинлегендә гамәлгә ашырыла.

## 5. Дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең, ә шулай ук аларның вазыйфаи затларының һәм дәүләт хезмәткәрләренең карарларына һәм кылган (кылмаган) гамәлләренә судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе

5.1. Дәүләт хезмәтен алучылар дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы ТР Биоресурслар буенча дәүләт комитеты хезмәткәрләре гамәлләрен (гамьсезлеген) судка кадәрге тәртиптә ТР Биоресурслар буенча дәүләт комитетына шикаять кылу хокукына ия. Комитет рәисе белән кабул ителгән карарларга шикаять Татарстан Республикасының Министрлар Кабинетына бирелә.

5.2. Гариза бирүче түбәндәге очракларда шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

дәүләт хезмәтен күрсәтү турындагы гаризаны теркәү срогы бозылу;

дәүләт хезмәтен күрсәтү срогы бозылу;

дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен, гариза бирүчедән Россия Федерациясе норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актларында каралмаган документларны яки мәгълүматларны яки гамәл кылуны таләп итү;

гариза бирүчедән, дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен, Россия Федерациясе норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актларында күздә тотылган документларны кабул итүдән баш тарту;

дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту, әгәр баш тартуның нигезләре федераль законнар һәм аларга туры китереп кабул ителгән Россия Федерациясенең норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актларында күздә тотылмаган булса;

дәүләт хезмәтен күрсәткәндә, гариза бирүчедән Россия Федерациясенең

норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актларында күздә тотылмаган түләү таләп итү;

ТР Биоресурслар буенча дәүләт комитеты, аның вазыйфаи заты, дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәргән ялгышларны һәм хаталарны төзәтүдән баш тарту яисә мондый төзәтмәләрнең билгеләнгән срогын бозу;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирү вакытын һәм тәртибен бозу;

әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актларында каралмаган булса, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору;

мөрәҗәгать итүчедән дәүләт хезмәте күрсәткәндә, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул иткән вакытта документларның булмавы һәм (яисә) дөреслеге күрсәтелмәгән документларны яисә мәгълүматларны таләп итү яки 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктында каралган очраклардан тыш, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту.

5.3. Шикаять кәгазь иядә язма яки электрон рәвештә бирелә.

Шикаять почта аша, күп функцияле үзәк аша,  яки электрон документ рәвешендә “Интернет” челтәрен кулланып, ТР Биоресурслар буенча дәүләт комитетының рәсми сайты аша(http://ojm.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең Интернет кабул итү бүлмәсе аша, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге аша, Татарстан Республикасының Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша, ә шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә тапшырыла ала.

5.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтүче әгъзага яки аннан югары торган әгъзага ( булган очракта) кергән шикаять теркәүдән соң 15 эш көне эчендә.  Әгәр дә документларны кабул итүдә яки ясалган хаталарны төзәтүдә яки андый төзәтүләрне ясау срогы бозылу очрагында, дәүләт хезмәтен күрсәтүче Комитет, аның вазыйфаи заты кире кагуына шикаять биргән очракта – аны теркәгәннән соң  биш эш көне эчендә каралырга тиеш.

5.5. Шикаять  түбәндәгеләрне үз эченә алырга тиеш:

1) гамәлләренә (гамьсезлегенә) шикаять бирелә торган ТР Биоресурслар буенча дәүләт комитетының, аның вазыйфаи затының яки дәүләт гражданлык хезмәткәренең исеме.

2)гариза бирүче-физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы булган очракта), яшәгән урыны турында белешмәләр, гариза бирүче –юридик затның урнашкан урыны турында белешмәләр, һәм шулай ук гаризачыга җавап бирү өчен элемтә телефонының номеры (номерлары), (булган очракта) электрон почта һәм почта адресы (адреслары);

3) ТР Биоресурслар буенча дәүләт комитетының, аның вазыйфаи затының яки дәүләт гражданлык хезмәткәренең шикаять кылына торган карарлары һәм гамәлләре (гамьсезлекләре) турында белешмәләр;

4)  ТР Биоресурслар буенча дәүләт комитетының, аның вазыйфаи затының яки

дәүләт гражданлык хезмәткәренең карарлары һәм гамәлләре (гамьсезлекләре) белән килешмәве буенча гаризачы тарафыннан китерелгән дәлилләр.

5.6. Шикаятькә, анда күрсәтелгән шартларны дәлилли торган, документларның күчермәләре кушылырга мөмкин. Андый очракта шикаятьтә, аңа кушылып бирелә торган документларның исемлеге күрсәтелә.

5.7. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча, дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган, түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1)шикаять, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган тарафыннан кабул ителгән карарны кире кагу, җибәрелгән хаталарны төзәтү, дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документлардагы хаталарны һәм җитешсезлекләрне төзәтү, аларны алу Россия Федерациясенең норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актлары белән каралмаган акча чараларын гаризачыга кайтарып бирү формасында канәгатьләндерелә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарту.

5.8. 5.7 пунктта күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән дә соңга калмыйча, гариза бирүчегә язмача һәм аның теләге буенча электрон формада шикаятьне карау нәтиҗәләре турында мотивлаштырылган җавап җибәрелә.

5.9. Шикаятьне канәгатьләндерелергә тиешле дип тану очрагында, мөрәҗәгать итүчегә җавапта дәүләт хезмәте күрсәткәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән бетерү максатларында Комитет тарафыннан гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенәләр һәм дәүләт хезмәте күрсәтү максатларында мөрәҗәгать итүчегә киләчәк гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.10. Шикаятьне канәгатьләндерелергә тиеш түгел дип тану очрагында мөрәҗәгать итүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында дәлилләнгән аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.

5.11. Шикаятьне карау барышында яки нәтиҗәсендә административ хокук бозу яисә җинаять кылу билгеләре ачыкланса, шикаятьне карау вәкаләтләре белән вәкаләтләнгән вазыйфаи зат кичекмәстән бар булган материалларны прокуратура органнарына юнәлтә.

Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән сирәк һәм бетү куркынычы яный торган төр хайваннарны ирексезлектә асрауга һәм киредән табигатькә кайтаруга рөхсәтнамәләр бирү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүнең административ регламентына 1нче кушымта

форма

Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән сирәк һәм бетү куркынычы яный торган төр хайваннарны ирексезлектә асрауга һәм киредән табигатькә кайтаруга рөхсәтнамә бирүгә гариза.

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты рәисенә

__________________________________________________________________________

(юридик затның тулы исеме, физик затның исем, фамилиясе, атасының исеме)

__________________________________________________________________________

(юридик һәм физик затның тулы адресы, физик затның паспорт мәгълүматлары)

__________________________________________________________________________

төр хайваннарны ирексезлектә асрауга һәм киредән табигатькә кайтаруга рөхсәтнамә бирүегезне сорыйм.

__________________________________________________________________________

(хайваннарның саны нинди төргә каравы,

__________________________________________________________________________,

женесе һәм яше)

асрау ______________________________ территориядә тормышка ашырылачак,

киредән табигатькә кайтару__________________________________________________

__________________________________________________________________вакыт ка

______________________________________________________________бәйле рәвештә

(хайваннарны тоту кирәклегенең кыскача нигезләмәсе)

__________________________________________________________________________

(фәнни-тикшеренү темалары кысаларында эшләр үткәрү очрагында, әлеге тема расланган,гыйльми киңәшмә беркетмәсенең датасы һәм номеры күрсәтелә , беркетмәдән тиешле өземтә гаризага кушымта итеп бирелә)

___________________________________________________________________

Хайваннарны асрау һәм киредән табигатькә кайтару өчен җаваплы зат

___________________________________________________________________

(фамилия, исем, атасының исеме, юридик затлар өчен - вазыйфа)

Гариза бирүченең имзасы___________________________________________

Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән сирәк һәм бетү куркынычы яный торган төр хайваннарны ирексезлектә асрауга һәм киредән табигатькә кайтаруга рөхсәтнамәләр бирү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүнең административ регламентына 2 нче кушымта

ТР МК 41нче номерлы карары белән расланган форма

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты

Татарстан Республикасы Дәүләт гербы

Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән сирәк һәм бетү куркынычы яный торган төр хайваннарны ирексезлектә асрауга һәм киредән табигатькә кайтаруга Рөхсәтнамә

________________________________________________________________

(хайваннар исемлеге)

_____________________________________________________________бирелде.

(юридик затның тулы исеме, физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме)

__________________________________________________________________

(юридик затның, физик затның тулы адресы, физик затның паспорт белешмәләре)

Рөхсәтнамәне биргән орган

____________________________________________________________________

______________________________________________

Бирү вакыты____________________ Гамәлдә булу срогы____________________

Нигез___________________________________________________________

Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән сирәк һәм бетү куркынычы яный торган төрләрне ирексезлектә асрауга һәм киредән табигатькә кайтаруга рөхсәт ителгән хайваннар исемлеге һәм саны:

| № | Төрнең исеме | саны |
|---|---|---|
| | | |
| | | |

Хайваннарны тоту урыны: ________________________________________

_____________________________________________________________________

__

Хайваннарны табигатькә чыгару урыны: ________________________________

_____________________________________________________________________

__

Хайваннарны тоту һәм табигатькә чыгару өчен җаваплы затлар:

_____________________________________________________________________

_____________________________________________________________________

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты рәисенең беренче урынбасары - табигатьне саклау буенча Татарстан Республикасының баш дәүләт инспекторы урынбасары имзасы

__________________________

Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән сирәк һәм бетү куркынычы яный торган төр хайваннарны ирексезлектә асрауга һәм киредән табигатькә кайтаруга Рөхсәтнамәнең икенче ягы

Рөхсәтнамәгә ______номерлы нәтиҗә

Рөхсәт бирү нигезләре ________________________________________

_____________________________________________________________________

Мәҗбүри рөхсәт шартлары:_____________________________________________

______________________________________________________________________________________________________________________________________________________________________________________________________________________________________________________________________________________________________________________________________________________

Рөхсәтнамәнең гамәлдә булу срогы:____________________________________

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты рәисенең беренче урынбасары - табигатьне саклау буенча Татарстан Республикасының баш дәүләт инспекторы урынбасары имзасы

__________________________

Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән сирәк һәм бетү куркынычы яный торган төр хайваннарны ирексезлектә асрауга һәм киредән табигатькә кайтаруга рөхсәтнамәләр бирү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүнең административ регламентына 3 нче кушымта

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты рәисенә

________________________

________________________________

(Ф.И.О., ( оешманың исеме, адрес (почта һәм(яки)электрон)

**Техник хатаны (хәреф хатасы, грамматик яки арифметик хата) төзәтү турында гариза**

Дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булып килгән документны төзегәндә җибәрелгән хата (хәреф хатасы, грамматик яки арифметик хата)турында хәбәр итәм.

____________________________________________________________________________________

(дәүләт хезмәте исеме)

_________________________________________________________________________язылган.

Дөрес мәгълүматлар:

_____________________________________________________________________________________

_____________________________________________________________________________________.

Дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булып килгән документны төзегәндә җибәрелгән техник хатаны(хәреф хатасы, грамматик яки арифметик хата) төзәтүегезне һәм ул үзгәрешләрне дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булып килгән документка кертүегезне сорыйм.

Киләсе документларны терким:

1. ______________________________________________________________
2. _______________________________________________________________
3. _________________________________________________________________

Җибәрелгән техник хатаны(хәреф хатасы, грамматик яки арифметик хаталар) төзүтүгә бирелгән гаризаны кире кагу турында карар кабул ителгән очракта, андый карарны электрон документ рәвешендә, киләсе электрон почтага җибәрүегезне сорыйм: ____________________________________________________________________________;

расланган күчермә рәвешендә кәгазь иядә, почта аша, киләсе адрес буенча: _______________________________________________________________________.

Үземнең, ә шулай ук мине алмаштыручы затның шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә (җыю, системалаштырыу, туплау, аныклау( яңарту, үзгәртү), куллану, тарату (шул санда тапшыру), шәхси үзенчәлекләрен бетерү, туктату, шәхси мәгълүматларны юкка чыгару, ә шулай ук дәүләт хезмәтен күрсәтү чикләрендә шәхси мәгълүматларны эшкәртү өчен кирәкле башка гамәлләр), шул санда автомат рәвештә,аларның кабул иткән карарын дәүләт хезмәтен күрсәтүче әгъза , дәүләт хезмәтен күрсәтү максаты белән, кабул итүне күздә тотып, рөхсәт бирүне раслыйм.

Раслыйм: минем һәм мине алмаштыручы затның гаризада бирелгән шәхси мәгълүматлары, ә шулай ук минем белән аста язылган мәгълүматлар дөрес. Гаризага өстәлеп бирелгән документлар (документларның күчермәләре), Россия Федерациясе кануннары белән билгеләнгән таләпләргә туры килә, гаризаны тапшырган вакытта, бу документлар гамәлдә һәм андагы мәгълүматлар дөрес.

Күрсәтелә торган дәүләт хезмәтенең сыйфатын билгеләү буенча сорауда катнашырга үземнең ризалыгымны бирәм. Телефон:_________________________.

____________________ ______________________ (_________________________)

(дата) (имза) (Ф.И.О.)

Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән сирәк һәм бетү куркынычы яный торган төр хайваннарны ирексезлектә асрауга һәм киредән табигатькә кайтаруга рөхсәтнамәләр бирү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүнең административ регламентына кушымта (белешмә өчен)

**Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән сирәк һәм бетү куркынычы яный торган төр хайваннарны ирексезлектә асрауга һәм киредән табигатькә кайтаруга рөхсәтнамәләр бирү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен җаваплы вазыйфаи затларның һәм әгъзаларның реквизитлары**

**Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты**

| Вазыйфа | Кабул итү вакыты | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|---|
| Рәис | Сишәмбе сәг.14.00 язылу буенча | 211-66-47 | ojm@tatar.ru |
| Рәис урынбасары | Сишәмбе сәг.14.00 | 211-75-06 | Ramil.Sharafutdinov0@tatar.ru |
| Идарә башлыгы | дүшәмбе: 14.00-18.00 | 211-68-62 | Rinat.Chispyakov@tatar.ru |
| Бүлек башлыгы | | 211-68-62 | Roza.Minnegulova@tatar.ru |

**Татарстан Республикасының Министрлар Кабинеты Аппараты**

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Җир асты байлыкларыннан файдалану, табигать ресурслары һәм әйләнә-тирә мохитне саклау мәсьәләләре бүлеге башлыгы | 264-77-78 | Marat.Fashutdinov@tatar.ru |